БАЛТАСИНСКИЙ РАЙОННЫЙ
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ РАЙОН
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

« 9 » апрель 2018 ел № 113

**2018 елда Балтач муниципаль районы территориясен чистарту буенча санитар-экологик икеайлык үткәрү турында**

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 23 мартындагы 593-р номерлы күрсәтмәсен үтәү йөзеннән һәм Балтач муниципаль районы территориясен санитар чистартуны тәэмин итү максатларында Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты **карар бирә:**

1. 2018 елның 1 апреленнән 31 маена кадәр Балтач муниципаль районы территориясен чистарту буенча санитар-экологик икеайлык (алга таба – икеайлык) игълан ителде.

2. Икеайлыкны үткәрү эшләрен координацияләү өчен оператив штаб төзергә һәм аның составын 1 нче кушымта нигезендә расларга.

3. 2018 елның 1 апреленнән 31 маена кадәр Балтач муниципаль районы территориясен чистарту буенча санитар-экологик икеайлыкны үткәрү планын 2 нче кушымта нигезендә расларга.

4. Балтач муниципаль районы шәһәр һәм авыл җирлекләре башлыкларына түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

- учреждение, оешма җитәкчеләренә һәм халыкка икеайлык үткәрү турында мәгълүматны җиткерү;
- җәмәгатьчелекне җәлеп итеп, икеайлык үткәрүне оештырырга;
- юлларны һәм тротуарларны, йорт фасадларын, урамнарны яктыртуны ремонтлау, зиратларны, паркларны, балалар мәйданчыкларын төзекләндерү, торак пунктлар территорияләрен яшелләндерү буенча конкрет чаралар күрергә;
- каты көнкүреш һәм биологик калдыклар полигоннарын (үләт базларын) тиешенчә карап тотуны һәм эксплуатацияләүне тәэмин итү һәм алар янәшәсендәге урыннарны санитар чистарту буенча чаралар күрергә;
- терлекчелек комплексларының рөхсәтсез калдык ташлау урыннарын бетерү буенча чаралар күрергә;
- үз карамагындагы территорияләрне санитар-экологик чистарту эшенә яшьләр (волонтерлар) оешмаларын ихтыяри рәвештә җәлеп итәргә;

- пляжларны, скверларны, паркларны, балалар мәйданчыкларын, азык-төлек һәм әйбер базарларын, халык күпләп ял итә торган урыннарны санитар чистарту буенча чаралар үткәрергә;

- икеайлыкны үткәрү эшләрен координацияләү өчен оператив штабка әлеге карарның 3 нче кушымтасы нигезендә икеайлык дәвамында эш барышы турында атна саен мәгълүмат тапшырырга.

5. «Благоустройство» ҖЧҖкә (Габдрахманов Н.Г.), «Чепья ТКХ КҖП» ААҖкә (Кадыймов М.Т.), шулай ук предприятиеләргә һәм оешмаларга чүп чыгару буенча махсус техниканың нәтиҗәле эшләвен һәм килгән каты көнкүреш калдыкларын кабул итү һәм күмү полигоннарының эшен тәэмин итәргә, контейнер мәйданчыкларын ремонтлау, каты көнкүреш калдыклары өчен контейнерлар әзерләү һәм ремонтлау буенча конкрет чаралар күрергә.

6. Балтач муниципаль районы административ комиссиясенә:

- җирлекләр территорияләрен төзекләндерү буенча муниципаль кагыйдәләрнең, калдыклар белән эш итү буенча муниципаль кагыйдәләрнең үтәлешенә контрольне көчәйтү өлешендә эшне активлаштырырга;

- Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгына әлеге күрсәтмәнең 3 нче кушымталары нигезендә атна саен пәнҗешәмбе көннәрендә, шулай ук әлеге күрсәтмәнең 4 нче кушымтасы нигезендә икеайлык үткәрү эшләренең барышы турында мәгълүмат (аңлатма язуы кушымтасы белән) бирергә - 2018 елның 12, 26 апреле, 10, 24 мае;

- Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына 5 нче кушымта нигезендә үткәрелгән чаралар нәтиҗәләре турында хисап тапшырырга - 2018 елның 12, 26 апреле, 10, 24 мае.

7. «Татмедиа ААҖ» филиалы «Хезмәт» газетасы редакциясенә (Зәкиев в.М.), «Кайтаваз» радиосы җитәкчесенә (Маннапова Г.С.) икеайлык үткәрүнең барышын массакүләм мәгълүмат чараларында даими яктыртуны тәэмин итүне тәкъдим итәргә.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Татарстан Республикасы
Балтач район башкарма комитеты
җитәкчесе Р. И. Шакиров